**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Кизләү авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

«21» ноябрь 2024 ел № 10

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Кизләү авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

Киекле авыл җирлегенең Кизләү авылы территориясендә яшәүче һәм теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә, балачак инвалидларын, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарын, СВОда катнашучыларны, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә?:

- эчәр су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- Кизләү торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, шул исәптән таш, ватылган кирпеч, туфрак, вак таш, ком, асфальт ватыклары (сатып алу ,ташу, салу), чокырларны ремонтлау (коелган асфальт);
- урамнарны яктырту җайланмасы (товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (халыкның күпләп ял итә торган урыннары (парклар, спорт мәйданчыклары, балалар мәйданчыклары һәм халыкның күпләп ял итә торган башка урыннары) товарларын (эшләрен, хезмәт күрсәтүләрен) сатып алу һәм аларга якын территорияне төзекләндерү);
- Кизләү торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;
- Кизләү торак пунктында ике традицион җирләү урыннарын төзекләндерү, коймалар кору, төзекләндерү.

Халык җыенында рәислек итүче: Л.И. Кашапова

Киекле авыл җирлеге башлыгы: Л.И. Кашапова